# Татарстанда чүп революциясе көтелә

**Чүпне аерым җыю, аны сортларга бүлү республика өчен иң киеренке проблема булып тора. Соңга калып булса да, әлеге мәсьәләне хәл итү юлларын эзли башладылар, бу өлкәдә беренче адымнар да ясалды. Татарстан Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының калдыклар белән эш итү бүлеге башлыгы Рөстәм Богданов сүзләренчә, пластик шешәләр җыю өчен республика буенча 1,2 мең челтәрле контейнер куелган, аның 600е Казанда урнаштырылган. Якындагы ике айда тагын 400 контейнер кую планлаштырыла.**

АКТУАЛЬ МӘСЬӘЛӘ




Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

– Казанда утильләшкән чимал кабул итү белән 30дан артык пункт шөгыльләнә. Киләчәктә чүпне аерым җыюга игътибар тагын да артачак. Моның өчен махсус «Максатчан күрсәткечләр» дигән территориаль схема гамәлгә ашырыла. Андагы күрсәткечләр буенча, 2025 елга чүп контейнерлары мәйданчыкларының 90 проценты көнкүреш каты калдыкларны аерым җыя торган итеп үзгәртеләчәк. Ә 2035 елга – 100 процент. 2025 елга утильләшкән чималны 165 пункт кабул итәр дип планлаштырабыз, 2035 елга – 313 пункт. Кыскасы, чүп революциясе көтелә, – дип сөйләде ул.

«Әйләнә-тирә мохитне саклау» дәүләт программасы кысаларында аеруча куркыныч калдыклар, әйтик, терекөмешле лампалар, градусниклар, батареялар җыю өчен дә махсус контейнерлар сатып алыначак. Быел андый чүп савытлары Казанда гына да 60 урында торачак. Киләчәктә ул, һәр авылда ук булмаса да, авыл җирлеге башкарма комитеты урнашкан салаларда да куелачак. Моның өчен муниципалитетларга субсидияләр бирергә уйлыйлар. Төбәк операторлары билгеләнеп, алар ныклап торып эшли башлагач, бу эш тагын да җанланып китәр сыман.

### ӨЙДӘ ИКЕ ЧҮП ЧИЛӘГЕ ТОРАЧАК

Чүпне аерып җыя башлагач, халыкка да өендә ике төрле чүп чиләге булдырырга туры киләчәк. Берсенә – ризык калдыклары һәм икенче чимал итеп кулланып булмый торган әйберләр, әйтик, авыр эшкәртелә торган композит ризык савытлары, икенчесенә икенчел чимал итеп кулланып була торган каты көнкүреш калдыклары салынып барылачак. Чүп ташу машиналары беренче чиләккә тутырып барылган чүпне көн дә алып китәчәк, ә икенче контейнердагыларны – берничә көнгә бер тапкыр. Аның өчен контейнерлар зуррак һәм биегрәк итеп эшләнәчәк.

Кайберәүләрдә бу, әлбәттә, ризасызлык тудырырга мөмкин. Янәсе, артык мәшәкать туачак, моның өчен халыкны кызыксындырырлык бернинди бонуслар да каралмаган. Элек кенә ул сөт, кефир шешәләрен җыеп тапшырып, акча эшләп булган. Казан федераль университетының Экология һәм табигатьтән файдалану институты директоры Светлана Селивановскаяның моңа үз җавабы бар.

– Германиядә бик күп танышларым яши. Анда шәхси йортларда өч секцияле чүп чиләкләре тора. Өйләре янында да ике контейнер куелган. Чүпне ялгышып кына берсе урынына икенчесен салмыйлар. Ни өченме? Чүпне тапшырганда ул контейнерда төрле калдыклар салынган булса, аны арзанрак бәягә алалар, ә аерып җыелган булса, бәясе күпкә зуррак. Бу алар өчен мена дигән бонус булып тора да инде. Кызганыч, бездә әлегә андый бонуслар бирүне караган закон юк, – ди ул.

Аның сүзләренчә, халыктан, чүпне аерым җыюны булдыру өчен нинди кызыксындыру алымнары кирәк дип уйлыйсыз, дигән социологик сораштыру уздырып була. Университетка мондый заказ бирсәләр, алар бик рәхәтләнеп эшләр иде.

### ПЫЯЛА КИРӘК ТҮГЕЛ?!

Шешәләр тапшыру дигәннән, бүгенге көндә пыялага ихтыяҗ юк диярлек. Бердән, аны икенче тапкыр куллану тыела. Икенчедән, пыяланы икенчел чималдан ясауга караганда, беренчел чималдан җитештерү арзанракка төшә. «Идел буе экология компаниясе» директоры Ольга Гудимова сүзләренчә, көнкүреш каты калдыкларының 5 проценты гына икенчел чимал итеп куллануга ихтыяҗ бар.

– Миңа калса, чүпне аерым җыю мәсьәләсе генә түгел, аны икенчел чимал итеп эшкәртү проблемасы да бар. Химия сәнәгате чимал эшкәртүгә караганда тизрәк темпта үсә. Күптән түгел генә кара төстәге чүп пакетларын кабат эшкәртүгә бик теләп алалар иде. Аңардан полимер эшләнде. Соңгы елларда пакетларга ихтыяҗ бетте, чөнки бу продукция Кытайдан керә башлады, ә алар аны эшләгәндә нәрсәдер кушалар, шуңа да аны һич эшкәртеп булмый. Куркыныч каты калдыкларга караган батарея, лампочкаларны җыю да отышлы түгел. Бер лампаны утильләштерү – җиде сумга, бер килограмм батареяны юк итү 300 сумга төшә. Элек аларны ИКЕА кибетендә җыялар иде, хәзер алар да җыймый, чөнки моңа лицензияләре юк, – ди ул.

Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының калдыклар белән эш итү бүлеге башлыгы Рөстәм Богданов журналистларга пыяланы икенчел чимал буларак кулланырга җыенуларын хәбәр итте.

– Министрлык пыяла савытлар базарында эшләүче бер эре компания белән сөйләшүләр алып бара. Әлеге компания икенчел чималдан пыяла блоклар эшләп чыгарырга җыена. Алар бездән республикада күпме пыяла савыт җыелуы белән дә кызыксынды. Завод бу эшкә тотынса, пыяла да икенчел чимал буларак кулланыла башлар, – ди ул.

### КАТЫРГЫДАН АКЧА КҮП КЕРӘ

Казанда макулатура, катыргы, пластик шешәләр җыю белән шөгыльләнүче «Чистая среда» компаниясе уңышлы эшли. Аларның берничә урында икенчел чималны кабул итү пунктлары да бар. Компания җитәкчесе Зарина Наумова сүзләренчә, иң файдалысы – катыргы тапшыру. Аны алып килгән әбиләр көненә 300-1000 сум акча эшли, ди.

– Халыктан икенчел чимал кабул итү пунктларының саны унга җитте. Безне беләләр, кызыксыналар, киләләр. Чималны эшкәртүче производстволарның саны күбрәк булса, без эшебезне тагын да киңәйтер идек, – ди ул.

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.**

# Сыерларга дерматит авыруы яный

**Оренбург өлкәсенең Ташлы, Ново-Сергеевский, Соль-Илецкий районнарында сыерларда төенле нодуляр дерматит авыруы башланган.**

– Бу районнар Татарстаннан 300-400 километрда гына, шунлыктан республикадагы сыерларга да авыру эләгү куркынычы бар, – дип хәбәр итте «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә Министрлар Кабинетының баш ветеринария идарәсенең терлекләрдәге йогышлы авырулар һәм йогышлы авыруларга каршы чаралар оештыру бүлеге җитәкчесе Александр Козлов.

Дерматит авыруын сыерларга черкиләр һәм озынборыннар йоктыра. Эссе климатлы Африка, Азия, Австралия һәм Көнчыгыш Европа илләрендә сыерларда бу эпидемия шактый еш күзәтелә.

– Оренбург өлкәсеннән тере мөгезле эре терлекне Россиянең башка өлкәләренә алып чыгу һәм сату чикләнде, – диде Александр Козлов. – Башкортстанда хәл имин, алар безгә терлекләр сата, чикләү юк. «Россельхознадзор» оешмасы да, без дә хәлне күзәтеп торабыз. Эпидемияле районнарны «Россельхознадзор» сайтыннан белешергә була. Сыерлардагы дерматит авыруы атларга, дөяләргә йокмый.

Мөгезле эре терлекләр сатып алуны көзгә салкыннар башланганчы кичектереп торсаң, ышанычлырак, дип киңәш итте ветеринар Александр Козлов.

Сыерда дерматит авыруы билгеләре: температура 40-41 градуска кадәр күтәрелә (сыерның тән температурасы 38 градус); күзеннән һәм борыныннан – сыекча, ә авызыннан күпләп селәгәй ага; ашамый; хәрәкәте салмак, ләкин агрессив; сыерның гәүдәсендә һәм имчәгендә 0,5-4 сантиметр диаметрда 0,5 миллиметр биеклектә төерчекләр барлыкка килә; сыерның сөте кызгылт төскә керә.

– Авыру йоктырган терлекне аерым бүлеккә ябарга һәм кичекмәстән антибиотиклар белән дәваларга кирәк. Көтүләрнең бер-берсе белән кушылуына юл куярга ярамый, – дип искәртте белгеч.

Авыру сыерга ялан кул белән тотынырга, сөтен кулланырга ярамый.

Татарстанның көньяк районнарындагы шәхси хуҗалыклардагы мөгезле эре терлекләргә вакцинация ясалачак.

Александр Козлов искә төшереп узганча, Татарстанда кош гриппы күзәтелү сәбәпле кертелгән карантин туктатылган. Лаеш кошчылык фабрикасында 528 мең тавык-чебеш юк ителгән. Бу хәл фабрикага 65 миллион сум зыян китергән. Лаеш кошчылык фабрикасында санитар чаралар әле хәзер дә дәвам итә.

**Дамир БӘДРИЕВ.**

**2022 елда Казан 25 метрга йөзү буенча дөнья чемпионаты үткәрәчәк.**

# Тагын йөзәбез икән

Бу көннәрдә Будапешт шәһәрендә Спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты бара. Аның кысаларында үткәрелгән ФИНА утырышында 25 метрга йөзү буенча дөнья чемпионатын кабул итүче шәһәр буларак Казан билгеләнде. Татарстан башкаласыннан тыш бу исемгә Будапешт (Венгрия), Кытайның Тайбэй белән Гонконг шәһәрләре дә дәгъва кылган иде.

Дөнья чемпионаты декабрь аенда булыр дип көтелә. 1200 спортчы алты көн дәвамында ярышачак.

– Бүген барысы да Россия, Казанның үсешен күрә, безгә ышана. Без дөнья чемпионатын инновацион чаралар кулланып үткәрергә тырышачакбыз. Әлегә моңа әзерләнү өчен вакыт бар. Ярышларның төп мәйданы Спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты, «Буревестник», «Олимп» спорт комплекслары булачак. Катнашучыларга Универсиада авылын да, кунакханәләрне дә тәкъдим итәчәкбез. Казанда иртәгә үк килеп, ярышлар оештырырлык. Моның өчен барысы да бар, – диде республиканың яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов.

Министр сүзләренчә, бүген Татарстанда заманча спорт объектларында урнашкан сигез балалар спорт мәктәбе эшли. Республикада 187 бассейнда 6 меңгә якын бала һәм яшүсмер шөгыльләнә.